КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 1 июнь г.Казань № 509

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре турында» 2021 ел, 30 декабрь, 1326 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре турында» 2021 ел, 30 декабрь, 1326 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

унынчы абзацта «Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 51 327,4 мең сум күләмендә финанслана торган» сүзләрен «Моношәһәрләрне үстерү фонды» коммерциягә карамаган оешмасыннан 54 721,211 мең сум күләмендә кергән акчалар һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслана торган финанс чыгымнары 50 579,85 мең сум күләмендә" сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Федераль бюджеттан бюджет кредитлары рәвешендә кергән акчалар исәбеннән финанслана торган инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән программаны 10 421 438,0 мең сум күләмендә;

2022 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы бюджеты акчаларының калган өлеше исәбеннән финанслана торган юл эшләре күләмнәре, Татарстан Республикасы исеменнән төзелгән товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә каралган, шушы дәүләт контрактлары шартлары нигезендә 2021 елда 777 862,62427 мең сум күләмендә түләнергә тиешле дәүләт контрактлары өчен түләүгә каралган 2020 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы бюджетының калган акчалары исәбеннән финанслана.»;

2 пунктта «35 550 978,34 мең сум» сүзләрен «46 804 252,62527 мең сум» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2022 елга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программасын, «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» ярдәмче программасының Каты өслекле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын авыл торак пунктларының якындагы иҗтимагый әһәмиятле объектларына, шулай ук авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү объектларына илтүче юлларны төзү һәм реконструкцияләү буенча чараларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән программаны, «Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проекты кысаларында автомобиль юлларын һәм ясалма юл корылмаларын норматив хәлгә китерүгә юнәлдерелгән программаны, «Төбәк, муниципальара һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын үстерүгә ярдәм» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында гомуми файдаланудагы төбәк яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлегенә юнәлдерелгән программаны, Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керә торган «Түбән Кама шәһәре» монопрофильле муниципаль берәмлегендә яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзүгә һәм (яисә) реконструкцияләүгә юнәлдерелгән программаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәләләр);

күрсәтелгән карарга әлеге дәүләт контрактлары шартлары нигезендә 2021 елда инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән программа белән түләнергә тиешле Татарстан Республикасы исеменнән төзелгән товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә контрактлар өчен түләүгә каралган 2022 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы бюджеты акчалары калдыгы исәбеннән 2022 елда финанслана торган юл эшләре күләмнәрен өстәргә (карарга теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин